| ГЛАВА<br>БУРУНДУКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь, 2025 ел Борындык авылы №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Борындык торак пунктында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 25 ноябренә 10 сәг 00 минутка Борындык авылы, К.Маркс урамы, 22А нче йорт адресы буенча урнашкан ФАП зданиесе янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2025 елның 26 ноябренә 14 сәг 00 минутка Борындык авылы, Октябрь урамы, 24 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2025 елның 27 ноябренә 10 сәг 00 минутка Борындык авылы, Октябрь урамы, 22 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Борындык авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм

даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны 2026 елда түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау(шул исәптән урам яктырткычлары, таймер, изоляцияләнгән чыбыклар сатып алу);
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү(шул исәптән территорияне, балалар мәйданчыгын чабу);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын, җиһазларны һәм ДЕПО бүлмәсен карап тоту);
- Янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;
- Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү».

«РИЗА» «КАРШЫ»?»

4. Әлеге карарны Борындык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавалылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Борындык авыл җирлеге Башлыгы** **А.Р.Гайнетдинов**

Совет Бурундуковского сельского поселения
Борындык авыл җирлеге Советы
ИНН 1621000541